БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«04» 06 2021 ел № 184

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясы, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Кушымта итеп бирелә торган Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гомуми-оештыру бүлеге башлыгына ярты елның соңгы аеннан соң килүче айның 10 числосына кадәр елга ике тапкыр гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ (алга таба - анализ) ясарга.

3. Балтач район башкарма комитетының гомуми-оештыру бүлегенең баш белгеченә соңгы айдан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча анализны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтына урнаштыруны тәэмин итәргә.

4. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гомуми-оештыру бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче А.Ф. Хәйретдинов

Балтач район башкарма комитетының
2021 елның «04» 06
184 номерлы карарына
кушымта

**Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибен**

1. Әлеге Тәртип «Россия Федерациясе гражданнары мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясын, «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 11 апрелендәге 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 23 статьясын үтәү йөзеннән эшләнде һәм Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына (алга таба – башкарма комитет) гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләрне (алга таба – мөрәҗәгатьләр) гомумиләштерү һәм анализлау процедурасын билгели.

2. Анализ үткәрелгәндә кергән, башкаларга кергәнне җибәрелгән һәм каралган язма мөрәҗәгатьләрнең саны, электрон документ формасында мөрәҗәгатьләр, гражданнарны кабул итү урыннары, көннәре һәм сәгатьләре турында, шәхси кабул итүдә кабул ителгән гражданнар саны, гражданнарны шәхси кабул итү һәм күчмә кабул итү буенча вәкаләтле затлар турында, мөрәҗәгатьләрнең тематикасы турында, мөрәҗәгатьләрне карау нәтиҗәләре буенча кабул ителгән чаралар турында, шул исәптән кабул ителгән норматив хокукый һәм башка актлар (булган очракта) турында мәгълүмат өйрәнелә.

3. Мөрәҗәгатьләрне гомумиләштерү һәм анализлау әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктлары нигезендә бирелгән язма мөрәҗәгатьләр, электрон документ һәм мәгълүмат нигезендә Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гомуми-оештыру бүлеге башлыгы тарафыннан гамәлгә ашырыла.

4. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе, аның урынбасарларының (алга таба - җитәкчелек) шәхси кабул итүләрендә кергән мөрәҗәгатьләр турында мәгълүмат җитәкчелекне шәхсән кабул итүгә гражданнарны язып баручы Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гомуми-оештыру бүлегенең әйдәп баручы белгечләренә тапшырыла.

5. Күчмә кабул итүләр буенча мәгълүмат башкаручылар тарафыннан Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гомуми-оештыру бүлеге башлыгына бирелә.

6. Әлеге Тәртипнең 4 һәм 5 пунктларында күрсәтелгән мәгълүмат Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гомуми-оештыру бүлегенең әйдәп баручы белгечләре тарафыннан 5 числога кадәр бирелә.

7. Мөрәҗәгатьләргә анализ Татарстан Республикасы Балтач муниципаль

районының рәсми сайтына урнаштыру өчен Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының гомуми-оештыру бүлегенең баш белгеченә җибәрелә. Анализ Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында ярты елның соңгы аеннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча урнаштырыла.

8. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында һәркем файдалана алырлык ачык мәгълүмат булып тора.